КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 29 август г.Казань № 1036

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2016 ел, 9 август, 541 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 15 февраль, 87 нче; 2017 ел, 30 сентябрь, 746 нчы; 2018 ел, 5 март, 135 нче; 2018 ел, 29 декабрь, 1316 нчы; 2019 ел, 19 апрель, 307 нче; 2021 ел, 30 декабрь, 1353 нче; 2022 ел, 23 декабрь, 1409 нчы, 2023 ел, 20 март, 293 нче, 2023 ел, 27 март, 362 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» 2005 елның 6 апрелендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив идарәсен үзгәртеп кору мәсьәләләре» 2016 елның 31 маендагы ПУ-491 номерлы Указы һәм Татарстан Республикасы Рәисенең «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары системасы һәм структурасы турында» 2023 елның 4 маендагы 276 номерлы Указы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

4 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

5 пунктта «2016 елга Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2015 елның 20 ноябрендәге 97-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы» сүзләрен «тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты турындагы нигезләмәдә:

1.1 пунктта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

2.1.3 пунктта «Татарстан Республикасының җирле үзидарә органнары» сүзләрен «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары» сүзләренә алмаштырырга;

«*» астөшермәсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«* Код билгеләнеше Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика башкарма хакимият органнары эшчәнлеген оештыру турында» 2023 ел, 26 июнь, 752 нче карары белән расланган Республика башкарма хакимият органнарының дәүләт идарәсе функцияләре кодификаторы нигезендә.»;

3.3 пунктның 3.3.16[1] пунктчасында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең бүтән башкарма органнарыннан» сүзләрен «бүтән республика башкарма хакимият органнарыннан» сүзләренә алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Коммерциячел булмаган оешма һәм халык хакимияте органының – Татарстан Республикасы дәүләт (муниципаль) архивын комплектлау чыганагының иң яхшы архивы» һәм «Коммерциячел оешманың – Татарстан Республикасы дәүләт (муниципаль) архивын комплектлау чыганагының иң яхшы архивы» республика конкурслары турында» 2018 ел, 1 октябрь, 889 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 24 март, 164 нче; 2021 ел, 21 июнь, 492 нче, 2022 ел, 04 июль, 634 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның өченче абзацында «дәүләт хакимияте башкарма органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган «Коммерциячел булмаган оешманың һәм халык хакимияте органы – Татарстан Республикасы дәүләт (муниципаль) архивын комплектлау чыганагының иң яхшы архивы» республика конкурсы турында нигезләмәдә:

1.3 пунктның икенче абзацында «дәүләт хакимияте башкарма органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

1.4 пунктның икенче абзацында «дәүләт хакимияте башкарма органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

1.5 пунктның өченче абзацында «дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

1.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.6. Конкурс турында белешмә, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы (тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы) кабул ителгән көннән соң килә торган 15 нче эш көненнән дә соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында (алга таба – бердәм портал) «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.»;

1.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.7. Акчалата бүләкләү тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән каралган бюджет ассигнованиеләре, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2016 - 2025 елларга Татарстан Республикасында архив эшен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2016 елның 10 июнендәге 395 номерлы карары белән расланган «2016 - 2025 елларга Татарстан Республикасында архив эшен үстерү» дәүләт программасы кысаларында бюджет акчаларын алучы буларак вәкаләтле органга билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.»;

1.9 пунктта:

беренче абзацта «дәүләт хакимияте башкарма органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«республика башкарма хакимият органнары;»;

2.1 пунктта «дәүләт хакимиятенең башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

2.4 пунктның беренче абзацында «дәүләт хакимияте башкарма органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

2.6 пунктның беренче абзацында «дәүләт хакимияте башкарма органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

3.3 пунктның бишенче абзацында «2.5» саннарын «2.6» саннарына алмаштырырга;

3.6 пунктның ундүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«сайлап алуда катнашучы чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булып тормауны раслый торган документ;»;

3.7 пунктта:

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«конкурста катнашучылар офшор компанияләре, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик затлары (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булып тормый. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами

акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;»;

4.3 пунктта:

өченче абзацта «дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«акчалата бүләкләү бирү тәмамлана торган төгәл дата һәм нәтиҗәсенең ахыргы күрсәткече (йомгакларның конкрет микъдари тасвирнамәсе);»;

унынчы абзацта «нәтиҗәгә ирешү» сүзләрен «нәтиҗә күрсәткеченә ирешү» сүзләренә алмаштырырга;

4.5 пунктның икенче абзацында «дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

5.1 пунктта «2.5» саннарын «2.6» саннарына алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган «Коммерциячел оешманың – Татарстан Республикасы дәүләт (муниципаль) архивын комплектлау чыганагының иң яхшы архивы» республика конкурсы турында нигезләмәдә:

1.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4. Конкурс турында белешмә, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы (тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы) кабул ителгән көннән соң килә торган 15 нче эш көненнән дә соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында (алга таба – бердәм портал) «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.»;

1.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.5. Грантлар тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән каралган бюджет ассигнованиеләре, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2016 - 2025 елларга Татарстан Республикасында архив эшен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2016 елның 10 июнендәге 395 номерлы карары белән расланган «2016 - 2025 елларга Татарстан Республикасында архив эшен үстерү» дәүләт программасы кысаларында баш бүлүче функциясен гамәлгә ашыручы һәм бюджет акчаларын алучы орган буларак вәкаләтле органга билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.»;

3.6 пунктның ундүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«сайлап алуда катнашучы чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия

юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булып тормауны раслый торган документ;»;

3.7 пунктта:

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«конкурста катнашучылар офшор компанияләре, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик затлары (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булып тормый. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;»;

4.4 пунктта:

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«грант бирү тәмамлана торган төгәл дата һәм нәтиҗәсенең ахыргы күрсәткече (йомгакларның конкрет микъдари тасвирнамәсе);».

сигезенче абзацта «нәтиҗәгә ирешү» сүзләрен «нәтиҗә күрсәткеченә ирешү» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган «Коммерциячел булмаган оешма һәм халык хакимияте органының – Татарстан Республикасы дәүләт (муниципаль) архивын комплектлау чыганагының иң яхшы архивы» республика конкурсында җиңүчеләргә акчалата бүләкләү түләү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү кагыйдәләрендә:

7 пунктта:

дүртенче абзацта «дәүләт хакимияте башкарма органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзацта «дәүләт хакимиятенең башкарма органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

алтынчы абзацта «дәүләт хакимияте башкарма органнарының» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнарының» сүзләренә алмаштырырга;

10 пунктта:

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«башка бюджетара трансферттан файдалану нәтиҗәләренең күрсәткечләре;»;

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«финанслашу максатларында башка бюджетара трансфертлар бирелә торган чыгымнар турында хисап һәм аларга ирешү максатларында кабул ителгән башка бюджетара трансфертлар һәм йөкләмәләр бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү турында хисап тапшыру тәртибе һәм сроклары;»;

12 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12. Вәкаләтле орган, башка бюджетара трансфертлар бирү елыннан соң килүче елның 1 февраленә кадәр, финанслашу максатларында Дәүләт комитетына Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән килешүнең бертип рәвешенә кушып бирелә торган формалар буенча башка бюджетара трансферт бирелә торган чыгымнар турында хисап һәм аларга ирешү максатларында кабул ителгән башка бюджетара трансфертлар һәм йөкләмәләр бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү турында хисап тапшыра (электрон рәвештә һәм кәгазь чыганакта).»;

13 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13. Башка бюджетара трансферт бирү нәтиҗәсе түбәндәгеләр була:»;

икенче абзацта «2.4» саннарын «2.6» саннарына алмаштырырга;

өченче абзацта «2.5» саннарын «2.6» саннарына алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин